

# Яз билгеләрен тап

Боз һәм кар эреде.
Сулар йөгерде,
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт
Я, әйтеп кара.

*Ел фасыллары. Г.Тукай*

Кояш көлеп карый безгә
Күзләр чагыла,
Елгалардан бозлар ага
Диңгез артына.
Яз, яз, яз җитә
Тәрәзәне ачтылар.
Тып-тып-тып итә
Эре-эре тамчылар.

*Яз җитә. Ф.Кәрим*

# Тема:Терек булмаган табигатьтә яз.

Бурычлар: 1.Терек булмаган табигатьтәге язгы үзгәрешләрне тану.
2. Язгы үзгәрешләр арасындагы бәйләнешләрне ачыклау.

# Бу даталар нәрсәне аңлата?

1нче сентябрь

23 нче сентябрь

1 нче декабрь

22 нче декабрь

1 нче март

21 нче март


# Язгы табигать күренешләре








# Терек булмаган табигатьтәге язгы үзгәрешләр



# Ял минуты:

Киң итеп җәеп колач *(кулларын як-якка җәяләр)*
Килде яз,  килде яз.  *(кул чабу хәрәкәтләре)*
Елмаеп тора кояш *(кулларны өскә күтәрәләр)*
Көн аяз, көн аяз .(*кул чабу хәрәкәтләре)*
Кыш буе яткан карлар
Эределәр, эределәр. *(кул хәрәкәтләре белән)*
Сыерчыклар, тургайлар.
Килделәр, килделәр.*(очу хәрәкәтләре ясыйлар)*

# Елгадан боз китә



# Онытмагыз!

Яз көне боз өстендә  йөрү куркыныч. Эрегән боз ярылырга мөмкин.

Елгадан  боз  киткәндә, язгы ташу чорында  сулык-лар янында уйнау куркыныч. Сезнең шаярулар бик күңелсез тәмамланырга мөмкин.



Ашытта су ташу күренеше



Беренче яшен

# Язын табигать уяна

Март Апрель Май







# Яз айларының халык биргән исемнәре

**Март** -кыш мөгезен сындыручы, яз борылу ае , нәүрүз ае, яз хәбәрчесе,мартта шарт, юлсыз ай, җилсез ай, кара каргалар кайту  ае, тамчылы ай, каен җәберләү ае.

**Апрель-** кар куучы, беренче чәчәк ае, кояшлы ай, язгы ташу ае, боз китү ае,ерганаклар ясалу ае, пар күтәрелү ае, басуга чыгу ае.

**Май-** үләннәр шыту ае, озын көннәр ае, сандугач ае, сөрү ае, сабан ае.

**Март:** кояш ныграк җылыта, температура күтәрелә, кар эри , тамчы тама, боз сөңгеләре, көннәр озая , язгы көн-төн тигезлеге, җилле, явым-төшем кар һәм яңгыр.

**Апрель:** кояш тагын да ныграк җылыта, җирләр кар-дан арчыла, елгалардан боз китә, язгы ташу,гөрләвек-ләр ага, ерганаклар ясала, җир дымга туена,пар күтә-релә, явым – төшем гадәттә яңгыр , температура түбә-нәйсә, кар булып та ява.

**Май:** температура югары, озын көннәр ае, беренче яшен, явым-төшем яңгыр.

# Үзеңне тикшер !

1.Язын температура ничек үзгәрә?

а) үзгәрми

***б) югары күтәрелә***

в) түбән төшә

2. Яз килү белән карның төсе үзгәрәме?

***а) әйе, ул соры төскә керә, көпшәкләнә***

б) юк

в) әйе, ул хәзер мамыктай йомшак

3. Яз җиткәч явым- төшемнәр явамы?

а) юк

б) яңгыр булып кына ява

***в) әйе, язын яңгырлар ява, ә кайчак кар***

4. Яз көне туфрак белән нәрсә була?

а) һәрҗирдә бер үк вакытта һәм бертигез эри

***б) әкренләп эри***

в) каты булып кала

5.Кайсы алданрак була: боз кузгалумы, әллә язгы ташумы?

а) берүк вакытта

***б) башта боз кузгала, аннан  соң  язгы ташу***

в) язгы ташудан соң гына боз кузгала.

6. Җөмләне тәмамла. Тиешле сүзләрне яз.

Кояш  кышка караганда  ***биегрәк***  күтәрелде. Көннәр  ***озайды*** , төннәр ***кыскарды .*** Көннәр  ***җылынды*** . Юеш  ***кар***  , яки  ***яңгыр*** ява. ***Кар , боз***  эри . Елгаларда  ***боз***  кузгала. Елга  кар һәм боз суы белән тула, ярларыннан ташып чыга. Елганың болай җәелүе ***язгы ташу*** дип атала.

7.Төркемнәргә бүл .

Февраль Март

тамчы суык боз сөңгеләре җил буран яктылык ае

# Өй эше :

**Мәҗбүри:**

1.Дәреслектәге материалны укы (62-65 нче бит), эш дәфтәрендәге 2 нче биремне үтә.

**Сайлап:**

1.Уен өйрән.

2. Яз турында 2-3 мәкальне истә калдыр.